**Туган көн безгә шатлык китерә**

1) Битемнән кояш уятты сөеп,
Бүген бит синең туган көн,  диеп.
Дәү үстең,  диеп, мактый әтием,
Өметем, диеп, назлый әнием.

Туган көннәрнең тылсым, сере бар.
Көн буе мине бар да котлыйлар.
Котлаган кебек тамчы гөлем дә,
Җыр бүләк итеп гөлләр телендә.

Кушымта:
Туган көндә дөнья
Нурга күмелә.
Туган көн безгә шатлык китерә.
Туган көндә бәйрәм
Ямьгә төренә
Туган көн ник елга, шул, бер генә?

Туган көндә дөнья
Нурга күмелә.
Туган көн бигрәк якын күңелгә.
Туган көндә бәйрәм
Ямьгә төренә
Туган көн ник елга, шул, бер генә?

2) Бүлешеп шатлык-куанычларым,
Бүләкләр белән килде дусларым.
Туган көнемдә шатлан, сөенче.
Җыр, бию белән тулсын өй эче.

Туган көннәрнең тылсым, сере бар.
Көн буе мине бар да котлыйлар.
Котлаган кебек тамчы гөлем дә,
Җыр бүләк итеп гөлләр телендә.